Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Март 2026

**Бу санда:**

2 -3 нче битләр “Бәйрәм белән, кадерле әниләр!”

Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет –
Һәр баланың
Үз әние булуы!

Минем әни, һич
бәхәссез,
Иң сөйкемле әни ул!
Әйткән сүзе,
Кылган эше –
Һәммәбезгә туры юл.

Борчыйсым килми
әнине,
Елмаеп, көлеп йөрсен.
Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен!




4-5 нче битләр – укучылар иҗаты

6-7 нче битләр “Сау бул, Әлифба”

8-12 нче битләр- гимназия сулышы




Яшь шагыйрьләр һәм язучыларның Бөтенрәсәй **“Илһам”** конкурсына иҗат иткән эшләр белән 5-6 нчы битләрдә танышырга була.



Гимназиянең 9 укучысы Республика олимпиадаларында призлы урынга лаек булдылар! Сез - безнең горурлыгыбыз һәм һәркем өчен үрнәк! Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабында җиңүчеләр һәм призёрлар турында газетабызның 8 нче битендә танышырга мөмкин.

# *Бәйрәм белән, кадерле әниләр!*



**Хөрмәтле хатын-кызларыбыз!!!**

Сезне язның тәүге бәйрәме – **Халыкара хатын кызлар көне** белән тәбрик итәбез. Хатын-кыз–ул тулы бер дөнья, аның күңеленә мәхәббәт тә, гүзәллек тә, йомшаклык та, иң көчле Ана хисләре дә, гаилә учагы жылысы да сыйган.

Бүген хатын-кызларның күпчелеге эш белән мәшгуль. Ул балалар да үстерә, йорт-җирне дә карый — аны якты һәм җылы итә, өстәвенә, карьера ясый һәм шушы мең төрле мәшәкатьләргә чумып калмыйча, үзенең нәзакәтлелеген дә саклый белә. Боларны бары тик хатын-кыз гына булдыра ала.

Сезнен тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызның күңел җылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан яктырып, нурлар чәчеп торса иде!



Җир йөзендә иң кадерле, иң матуры - ул минем әнием! Аның исеме Ильмира Васильевна. Ул Минзәлә гимназиясендә инлиз теле укытучысы булып эшли. Аңа 42 яшь. Без әни белән өйдә йога белән шөгыльләнәбез. Төрле тәмле ризыклар пешерергә дә мине әнием өйрәтә. Минем әнием бик акыллы, тәҗрибәле. Мин әниемне халыкара хатын-кызлар бәйрәме белән котлыйм. Аңа ныклы сәламәтлек, авыр, ләкин мактаулы хезмәтендә уңышлар, бәхет телим. Мин әниемне бик-бик яратам. Кызың Айзирә.

*****

Минем әниемнең исеме Роза. Аңа 37 яшь. Ул тикшерү изоляторында баш бухгалтер булып эшли. Минем әнием иң матуры, иң мәрхәмәтлесе. Ашарга оста пешерә белүе белән дә ул башкалардан аерылып тора. Әле әнием математика фәнен дә бик яхшы белә. Миңа өй эшләрен әзерләгәндә дә бик теләп булыша. Минем әни бөтен кешене дә алыштыра ала, тик аны гына беркем дә алыштыра алмый. Авыр вакытларымда мине аңлый белә. Ә инде авыра калсам, кырымнан да китми, минем өчен бик кайгыра, мине дәвалый. Әниемне язның беренче бәйрәме-8 нче март белән котлыйм. Әлбәттә инде ныклы сәламәтлек һәм бәхет телим. Әниемә күбрәк ял тисен иде, чөнки ул бик күп эшли. Мин аның белән горурланам. Кызың Азалия.

*****

Минем әниемнең исеме – Ләйсән. Ул-волонтёр, махсус хәрби операциядәге солдатларга посылкалар, тәмле ашлар әзерләшә. Ул бик тырыш. Үзенең эшен һәрвакыт җиренә җиткереп башкара. Тәмле ашлар да пешерә. Бигрәк тә миңа матур, төрле прическалар ясарга ярата. Мин әниемне бик яратам. Аңа бәхет, шатлык, озын гомер, ныклы сәламәтлек телим. Кызың Рузилә.

*****

Минем әниемнең исеме-Лилия. Ул Яр Чаллы шәһәрендә эшли. Әнием бик оста ашарга пешерә. Хәтта шеф-поварларны да уздырып җибәрә. Мин әниемне бик яратам. Аңа озын гомер, уңышлар, бәхет телим. Барлык теләкләрең дә тормышка ашсын, әнием! Улың Ислам.

*****

Минем әниемнең исеме Фирзия. Аңа 36 яшь, ул медицина училищесында эшли. Ул - җир йөзендә иң шәп әниләрнең берсе. Чөнки минем әнием сыман, тәмле итеп, мантый һәм пилмән пешерә белүче юктыр. Өч бала тәрбияләп үстерә. Барыбызга да вакыт таба, ярдәм итә. Без аны бик яратабыз. Озак яшә, әнием, һәм бәхетле бул. Кызың Шигапова Әминә.

*****

Минем әниемнең исеме - Лилия. Әниемә 45 яшь. Ул – умартачы. Минем өчен әнием-иң якын, иң игелекле, иң унган, иң матур, иң якын кешем. Ул тәмле ризыклар әзерли, тегәргә ярата. Аның әле шундый сыйфаты бар: ул электричествоны бик яхшы белә. Әниемне 8 нче март бәйрәме белән котлыйм. Әниемә бәхет һәм сәламәтлек телим. Кызың Камашева Әминә.

*****

Минем әниемнең исеме - Лилия. Аның туган көне 7 нче ноябрь. Мин әнием белән бик күп вакытынны бергә үткәрәм. Ул бик матур киенергә ярата. Әле ул спорт белән дә шөгыльләнә. Аның иң яраткан спорт төре - ул чаңгыда шуу. Саф һавада булу, спорт белән шөгылләнү -ул сәламәтлек өчен бик файдалы. Мин яраткан әниемә озын гомер, корычтай ныклы сәламәтлек телим. Кызың Исламия.

*****

Минем әниемнең исеме- Эльмира Рамилевна. Аңа 31 яшь. Әнием буш вакытын бушка үткәрергә яратмый. Әнием вакытлыча өйдә, декрет ялында әле. Шулай булса да, вакыт табып, төрле иҗади әйберләр ясый, мунчалалар бәйли. Әниемә алмаз мозаикасыннан картиналар җыю бик ошый. Безнең өйдә андый картиналар берничә инде. Әниемә һәрвакыт шулай ягымлы, чибәр булып калуын телим. Мин аны бик-бик яратам. Кызың Анастасия.

<u>*Материалларны Федотова Әдилә әзерләде*</u>

## ***«Минем әнием» темасына югары сыйныф укучылары иҗаты***











# Яшь шагыйрьләр һәм язучыларның Бөтенрәсәй “Илһам” конкурсына укучылар иҗаты

**Алинә һәм куянкай.**

Кышкы матур, салкын көнне Алинә мәктәптән өенә кайтып бара иде. Ул агач янында моңсу гына карап утырган йонлач куянны күрде. Кызга җәнлек кызганыч булып китте, чөнки кыш салкын һәм карлы иде, һәм аның аңа ничек тә ярдәм итәсе, ашатасы килде.

Алинә рюкзагыннан алма һәм икмәк кисәге алып, аларны куянга сузды. Куян тиз генә сыйны ашап бетерде һәм рәхмәт йөзеннән кызга карады.

Аннары кинәт кеше тавышы белән сөйли башлады.:

“Рәхмәт сиңа, мәрхәмәтле кыз! Мин үземне ашаткан кешегә күптән рәхмәт әйтмәкче идем. Син бик тә тәрбияле кыз икәнсең. Хәзер минем дустым бар!”

Алинә гаҗәпләнде, ләкин яңа танышуга шатланды. Алар бергәләп урман буйлап йөрергә, хайван эзләрен карарга һәм кар астында җиләкләр эзләргә киттеләр. Куянкай Алинәгә урман тормышын сөйләде,җәнлекләр телен дә бераз өйрәтте. Бик озак саф урман һавасын сулап йөргәннән соң,Куян кызчыкны өенә озатып куйды.Алар һәр ел саен очрашырга сөйләштеләр.

Ә кичен, йоклар алдыннан, Алинә Кыш Бабайга хат язды, яңа дустына Җылы өй һәм бик күп тәмле алма бүләк итүен үтенде.

Иртә белән Алинә уянды һәм тәрәзә төбендә «куян Дустым өчен»дип язылган кечкенә агач йорт күрде. Янәшәдә алма һәм кишер ята. Алинә үзенең теләге аның яхшылыгы аркасында тормышка ашканын аңлады.

***Айнетдинова Азизә***

*****

**Әбиемә**

Син бит минем иң якыным,
Иң кадерлем, иң зур кешем.
Синең йөрәк җылың белән
Бәхетле булып үстем.

Кулларыңның изгелеге
Ялт итәдер күз алдында.
Син догада, син назда да,
Син гел минем уйларда.

Әбием, сиңа сәламемне
Җилләр китереп җиткерсен.
Озын гомер, саулык-сәламәтлек
Ходаем үзе бирсен!

***Гараева Илиза***

*****

## Туган тел

Туган телне өйрәнергә кирәк,
Кайда гына булсаң да.
Туган тел-ул синең өчен газиз
Еракларда торсаң да.
Туган тел ул-әнкәй теле,
Бишектә яңгыраган.
Буыннан-буынга күчеп,
Хәтта көйгә салынган.
Туган телне онытма, син,
Һәрчак сөйләш үз телеңдә!
Рәхәтләнеп җырла, бие,
Горур бул, син, үз илеңдә!!!

***Гарипова Нәргизә***

*****

**Минем беренче остазым**

Һөнәрләрнең бар җайлысы, һөнәрләрнең бар яхшысы, һөнәрләрнең бар авыры… Ә укытучы хезмәте — иң изге һөнәрләрнең берсе. Укытучы — ул балаларны укыта, тәрбияли. Үзе тәрбияләп, “зур тормышка” озаткан балаларның уңышларын, бөртекләп, барлап торган педагогның акыллы да, матур да фикерләре һәр укучының күңелендә урын ала. Ә укытучы күңелендә-горурлык хисе. Бакчачы гөлбакчада үскән гүзәл гөлләре белән мактангандай, чын укытучылар да чәчәкләре җимешләнгән укучылары белән соклана. Шулай булмый ни, бер бала тәрбияләп үстерү генә дә ни тора, ә дистәләгән-йөзләгән нарасыйны җәмгыятькә кеше итеп әзерләп бирү күпме көч, күпме сабырлык, никадәр нур сорый?! Шул фидакарьлек, күңел юмартлыгы элек-электән аерып торган бит инде аларны! Аларның изге күңеллелеге, алиһәдәй бөек, әнидәй якын кеше дәрәҗәсенә күтәрә. Ә без, укучылар, үз чиратыбызда, үзебез

ирешкәннәрне алар алдында горурланып күрсәтергә, алар белән уртаклашырга ашыгабыз. Минем беренче укытучым - Раушания Шамиловна. Ул икенче укытучыларга охшамаган, аның үзенә генә хас яклары бар. Кайвакыт безнең белән шаяра да, кычкырып та көлә, безгә һәрвакыт булышып тора. Раушания Шамиловна бер эштән дә читтә калмый. Ул искиткеч укытучы. Ул безгә барлык фәннәрдән дә ныклы нигез бирде һәм безгә тырыш хезмәтнең һәм тугрылыкның мөһимлеген өйрәтте. Раушания Шамиловна сыйныфта дәресләрне кызыклы һәм мавыктыргыч итә белә иде, бу бездә укуга мотивация һәм кызыксыну уятты. Аннан өйрәнгән иң мөһим нәрсә – белем - көч. Ул безне беркайчан да өйрәнүне туктатмаска һәм яңа идеялар белән янып яшәргә өйрәтте. Раушания Шамиловна - бик яхшы һәм житез укытучы. Безгә белем бирде һәм алда да ул безгә киңәшләр биреп тора. Аңласын өчен ул безгә 1нче класстан ук дәресләрдә видеолар, презентацияләр күрсәтеп бара иде. Раушания Шамиловна миңа бик ошый. 4 ел эчендә бик күп нәрсәгә өйрәтте ул безне. Чын күңелдән аңа рәхмәтемне җиткерәсем килә.

***Галиева Язгөл***

*****

**Тукай туган көн**

Җиһан тулы шигъри аваз,
Тирә-якка сихри моң.
Кошлар да җырга кушыла,
Бүген-Тукай туган көн.
Табигать тә иркен сулый,
Төннәр якты, гүя, көн.
“Туган тел”не, “Шүрәле”не –
Тукаебыз туган көн.
Һәрбер йортка бәрәкәтле
Шатлык килә торган көн.
Күңелләрдә бәйрәм хисе –
Бүген Тукай туган көн!

***Федотова Ясминә***

*****

**Мин-Минзәлә кызы**

Назлый аны иртән искән җилләр,
Шәһәремне кояш сәламли.
Әкрен генә яуган яңгырлар да
Минзәләмне коча, иркәли.
Күргәнем бар байтак шәһәрләрне,
Матур алар – күреп шаккатам.
Минзәләгә җитми барыбер, дип,
Шатлыгымны җилгә таратам.
Төзекләнә бара Минзәләбез
Юбилеен бәйрәм итәргә.
Җыелырлар бик-бик ераклардан
Тарих йомгакларын сүтәргә.
Мин- Минзәлә кызы – горурланам!
Язмыш мине кая илтсә дә,
“Миндәләнең кыдыл бодавы”,- дип
Исем китми, читләр әйтсә дә.

***Федотова Әдилә***

*****

**Язгы матурлык**

Кояш көлә күк йөзендә,
Яз килә безнең якка.
Шатлык нуры һәр күңелдә
Наз өсти табигатькә.
Ераклардан кошлар кайта,
Сайрыйлар бакчаларда.
Яшел үлән баш калкыта
Ямь биреп кырларга да.
Туган ягым, гүзәл җирем
Сине күңел ярата.
Яшәсен мәңге бу илем,
Ямь өстәп бу дөньяга.

***Даутова Ләйлә***

*****

**Туган телем.**

Татарстан-туган җирем,
Татар теле-туган телем!
Башка телне өйрәнсәң дә
Үз телеңне яхшы бел син!
Туган телем-татар теле
Мин шул телдә сөйләшәм.
Әткәемә-әнкәемә
Саф татарча эндәшәм.
Туган илне, туган җирне,
Туган телне яратам.
Беркайчан да үз телемне,
Үз илемне онытмам.

***Горбунова Розалина***

*Эшләрне Салахова Зилә җыйды*

# *Сау бул, Әлифба!*




6 нчы март көнне, беренче сыйныф укучылары өчен зур мәктәп дәреслегенең кечкенә бите әйләнеп капланды, аларга иң беренче китап — Әлифба белән хушлашырга туры килде. Әлифба белән хушлашу чын-чынлап тантаналы һәм матур узды. Укучылар белем бирүнең мөһим этабын уңышлы тәмамлауларын, алфавит нигезләрен үзләштерүләрен раслаучы беренче мөһим дипломнарын алдылар. Ленар Миңнемуллинның җыр башкаруы бәйрәмнең матур бизәге булды. Җылы музыка һәм якты хисләр сабыйларның үзләрендә дә, өлкән тамашачыларда да чын соклану уятты. Моннан тыш, аеруча игътибарны әниләрнең чыгышлары җәлеп итте, алар үзләренең яраткан балаларын матур бәйрәм җырлары белән котладылар. Бу назлы нота чарага үзенчәлекле төсмер өстәде, аны һәр катнашучының йөрәгенә тагын да якынрак һәм якынрак итте. Шулай итеп, бүгенге бәйрәм беренче сыйныф укучыларыбызның мәктәп тормышының мөһим өлешен уңышлы тәгәлләде, алар алдында танып белүнең һәм ачышларның яңа мавыктыргыч юлын ачты.

Бәйрәмгә килүче ата-аналарның да йөзләре көләч, шатлык белән тулы. Без аларның нинди хисләр кичерүен белештек:

**Ильсинә Миннемуллина:**

Гимназиядә 1 нче сыйныф укучылары Әлифба китабы белән саубуллашты. Укытучыбыз Рузилә Рәуфәт кызына рәхмәтләребез чиксез. Үзенең көчен кызганмыйча безнең балаларга матур бәйрәм ясады. Бу бәйрәм кеше күңелендә иң истә кала торган бәйрәмнәрнең берсе. Әлифба бәйрәмендә укучылар татар һәм рус телендә шигырьләр сөйләделәр, җырладылар. Әти-әниләрдә читтә калмады, җырлар бүләк иттеләр, бәйгеләрдә катнашып бүләкләр дә оттылар. Ә бәйрәм ахырында һәр укучы директорыбыз Лилия Альберт кызы кулыннан диплом алды. Бу тагын да балага алга таба тырышып укырга көч өсти. Әлифба - барыбыз өчен дә зур бәйрәм һәм тантана ул. Әлифба бәйрәме – мәктәп елларында истә кала торган иң тәүге бәйрәмнәрнең берсе.

*****

**Зифинә Валиева (Риананың әбисе)**

6 нчы март көнне гимназиядә әлеге бәйрәм булып үтте. Кичә генә кыяр-кыймас, мең сорауга җавап табарга теләп мәктәп ишеген ачып кергән оныгым Риана беренче җиңүен бәйрәм итә. Беренче укытучысы Рүзилә Рәүфәт кызына булган хөрмәт, ышаныч күзләрендә чагыла иде.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. 1 нче сыйныф укучылары тәүге дәреслекләкләре – Әлифбаны укып тәмамладылар. Алар, Әлифбага багышлап, җырлар җырладылар, сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләделәр, биеп тә күрсәттеләр. Әниләр дә бик матур итеп җырладылар.

Укытучы апалары һәрбер баланы матур теләкләре белән сәхнәгә чакырды.

Бәйрәмгә укучыларның әти-әниләре, әбиләре дә килгән иде, чөнки Әлифбаны тәмамлау аларның да зур җиңүе булып исәпләнә. Бала тәрбияләүдә әти-әни, укытучы, укучы кулга-кул тотынып эшләгәндә генә югары уңышларга ирешергә мөмкин шул.

Бәйрәмдә катнашучыларның йөзләрендә тагын бер кат шатлык хисләре балкыды. Ә укучыларга Әлифбаны яхшы тәмамлауларының нәтиҗәсе итеп Дипломнар тапшырылды.

Киләчәктә әлеге укучыларга белем серләренә төшенергә, бөек үрләр яуларга насыйп булсын!




**Яковлева Эльвира:**
«Әлифба белән хушлашу» — ул бәйрәм генә түгел, ә безнең гаилә тормышының бер өлеше. Ул көнне барысы да шатлык, елмаю һәм якты хатирәләр белән тулы иде. Безнең балабыз сәхнәдә горурланып чыгыш ясады, ә без бәхет яшьләрен тыя алмадык! Бу бәйрәм аның белем дөньясына беренче адымнарының символы булды, һәм, аның балкып торган күзләренә карап, без балага бу юлда ярдәм һәм мәхәббәт күрсәтүнең никадәр мөһим булуын аңладык. Бу безнең барыбыз өчен дә бик күңелле момент.

*****



**Шаймуратова Гөлчәчәк:**
Безнең гаилә өчен "Әлифба бәйрәме" чын мәгънәсендә үзенчәлекле көнгә әверелде. Кызыбызның үзенә зур белем дөньясына юл ача торган беренче китабын горурланып тотуын күрү гаҗәеп дулкынландыргыч булды. Бу бәйрәм-әлифбаны өйрәнүнең ахыры гына түгел, ә үсеп җитү өчен мөһим адым. Кызым һаман да чыгышлардан тәэсирләнгән һәм үзен чын "олы" укучы итеп хис итә, хәзер ул теләсә нинди әкиятне үзе укый ала!

*****

**Мөкәрәмә Мадишина (Ралинаның әбисе)**
Тормышта барысы да кечкенәдән башлана: бөртектән-икмәк, Нурдан-кояш, кирпечтән - йорт, ә белем һәр кешенең беренче китабыннан - Әлифба. Менә бүген бездә дә "Әлифба" бәйрәме узды. Ул балаларыбызның мәктәптә беренче җиңүенә багышланган иде. Тырышлык һәм теләге аркасында укучылар барлык хәрефләрне өйрәнделәр, укырга һәм язарга өйрәнделәр. Беренче сыйныф укучыларыбыз бәйрәмгә киенеп килделәр. Актлар залы бәйрәмчә бизәлгән иде. Балаларның сәхнәгә чыгуы характеристика белән үрелеп барды, биредә укытучыбыз Рузилә Рәүфәт кызы һәр укучыны аерып күрсәтте. Әти-әниләре һәм кунаклар аларны көчле авацияләр белән каршы алдылар. Концерт номерлары бик шәп, барысы да тырыштылар. Монда сыйныф җитәкчесе хезмәте. Безнең балаларыбызның йөзләрендә елмаю балкыды, бу искиткеч. Балалар бик күп бүләкләр алдылар, бөтен бәйрәмгә сокланып карадылар. Ул бик шәп кеше: алар аны озак истә калдырырлар. Бәйрәмегез өчен зур рәхмәт, безнең укытучыга "5".




<u>*Гарипова Нәргизә әзерләде*</u>

# Гимназия сулышы



Яшь генийларның иртәнге сәгате: гимназиядә Бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабында җиңүчеләрне һәм призёрларны хөрмәтләделәр! Бүген безнең мәктәптә аерым атмосфера хөкем сөрде - горурлык, триумф һәм лаеклы танылу атмосферасы. Без иң акыллы, иң талантлы, иң максатчан - катлаулы биремнәрдән курыкмаган һәм олимпиаданың муниципаль этабында гимназияне бик яхшы тәкъдир итүчеләрне хөрмәтләдек. Аеруча соклану сүзләре - берьюлы берничә фән буенча җиңүгә ирешкән укучыларга! Бу уңыш кына түгел, бу - зур хезмәт!!! Сез - безнең горурлыгыбыз һәм һәркем өчен үрнәк! Без сезгә ирешелгәннәрдә тукталып калмаска һәм яңа үрләр яулап алырга телибез. Киләчәктә республика биеклекләрендә күрергә язсын сезне, кадерле укучыларыбыз!!!!

*****

Ел саен Татарстан Республикасының һәм Россия төбәкләренең уку йортлары базасында Сәләт берләшмәсе төбәк "Сәләт" клублары эшчәнлеген оештыра. Шул уңайдан, 26 нчы февраль көнне Казан шәһәрендә Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә XI "Сәмрүх" республика ел премиясен тапшыру тантанасы узды. Еллык эшчәнлеккә нәтиҗә ясау максатыннан, "Сәләт-Минзәлә" клубы активистлары Сәләтле балаларны һәм яшьләрне үстерү өлкәсендә XI "Сәмрүх" республика ел приемиясенең "Ел клубы" номинациясендә катнаштылар.



*****



Безнең 10 нчы сыйныф укучысы Галиев Аяз Фаяз улы ОБЗР буенча Бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабында призер булды. Бу безнең гимназиябез өчен зур казаныш! Аяз бу максатка максатчан бара: әзерлек 9 класста ук башланган. Артта - практика километрлары һәм теория таулары. Житәкче Сәмигуллин Марат Митхатович белән бергә ул һәр элементны җентекләп тикшерде: тренажерлардан алып, урынның махсус планлаштырылган участогында ориентлашуга кадәр. ОБЗР буенча призер булу - белем һәм физик

әзерлекне тоташтыра белү дигән сүз. Гамәли турларда һәр хәрәкәт мөһим, һәм Аяз анын иң яхшы булуын раслады. Без синең белән горурланабыз, Аяз!!! Уңышлар гына юлдаш булсын сиңа!!!

*****



Яз игелекле эшләрдән башлана! Беренче хәрәкәтнең активистлары 8 мартны көтмәскә, ә бәйрәм кәефен хәзер үк тудыра башларга булдылар! Шушы көннәрдә генә без балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә кунакка кердек. Бу көлке һәм иҗат белән тулы иртә иде. Егетләр белән бергә без яраткан әниләр һәм әбиләр өчен бәйрәм открыткалары ясадык. Кәгазьдәге һәрбер чәчәктә шулкадәр тырыш хезмәт! Укучылар балаларның зирәклеген тикшерделәр: язгы табышмакларга җаваплар таптылар һәм чараның темасы белән бәйле сорауларга җаваплар бирделәр. Һәм, әлбәттә, без сюрпризсыз китмәдек! Без балалар белән яхшы, шаян видео төшердек. Балалар үзләре өчен кечкенә бүләкләр алдылар, шулай ук үз куллары белән әниләр һәм әбиләр өчен бүләкләр ясадылар, ә безнең мәктәп укучыларының тәҗрибәсе аларга һичшиксез кирәк булачак. Барысы да канәгать калдылар!

*****




Минзәлә районы укучылары Җиңү Поезды белән очрашты. Иң актив белем бирү учреждениеләре укучылары Татарстан Республикасының Чаллы шәһәрендә “Җиңү поезды” тематик экспрессы очрашуына багышланган тантаналы чарада катнаштылар. Оештырылган сәфәр укучыларга поездның тарихи экспозициясе белән танышырга, сугыш еллары атмосферасын тоярга һәм Бөек Ватан сугышы геройларын искә алырга мөмкинлек бирде. Яшьләрнең катнашуы Ватаныбызның тарихи мирасына патриотизм һәм хөрмәт тәрбияләүгә ярдәм итә.

*****




Безнең активистлар үзләренең юл йөрү кагыйдәләрен белүдә генә түгел, спортта да иң яхшы икәнлекләрен исбатлады! Безнең мәктәпнең ЮИД отряды командасы шәһәр мәктәпләре арасында мини-футбол буенча 2 нче урынны яулады. Балалар чын характер һәм җиңүгә ихтыяр күрсәтеп, якты матчлар сериясен уздырдылар. Бик яхшы нәтиҗә белән котлыйбыз һәм яңа җиңүләр өчен җан атыйбыз!

*****



18 мартта, Кырымның Россия белән кушылу көнендә, гимназия интернатында бу

вакыйгага патриотизм тәрбияләү, Россия өчен ярымутрауның тарихын һәм әһәмиятен өйрәнү максатыннан багышланган әңгәмә үткәрелде. Балаларга Кырымның Алтын Урда чорындагы тарихы турында сөйләделәр. 2014 елның март вакыйгалары тасвирланган, Герой Севастополь шәһәре - "рус диңгезчеләре горурлыгы" турында мәгълүмат аеруча зур кызыксыну уятты. Әңгәмә вакытында төп акцент Кырымның Россия белән яңадан берләшүе, Россиянең тарихи гаделлекне кире кайтарган заманча тарихында төп этап булды.

*****



Чаллы шәһәренең 52 нче мәктәбендә "Илһам" бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең зона этабы үтте. Актаныш, Минзәлә, Зәй, Алабуга, Әгерҗе, Тукай районнарыннан килгән яшь язучылар поэзия, проза, журналистика, драматургия һәм тәрҗемә жанрында иҗади осталыкларын күрсәттеләр. Быел әлеге бәйгегә 600 дән артык эш кабул ителеп, зона этабына 300 баланың иҗади эшләре сайлап алынган. Минзәлә районыннан 17 укучыга чакыру килде, шуларның ундурте- гимназия укучылары. Бүген балалар һәр номинациядә уңышлы чыгыш ясап, 1 нче тур җиңүчесе дипломы белән бүләкләнде. Укучыларның эшләрен мәртәбәле жюри: күренекле сәнгать әһелләре, язучылар, шагыйрьләр белән берлектә Мәгариф һәм фән министрлыгы милли мәгарифнең әйдәп баручы консультанты Зөлфия Тәлгать кызы Закирҗанова да бәяләде. Укучыларны бу җиңүләре белән котлыйбыз!

*****



Минзәлә шәһәре гимназиясендә укучылар Лубян урман-техника көллияте делегациясе белән очрашты. Чара өлкән сыйныф укучыларын профориентацияләүгә һәм урман хуҗалыгы, экология өлкәсендә белем алу мөмкинлекләре белән танышуга юнәлтелде. Көллият вәкилләре укучыларга уку йортында үзләштерергә мөмкин булган белгечлекләр, хезмәт базарында белгечләргә ихтыяҗ булу һәм эшкә урнашу перспективалары турында сөйләделәр. Студентлар укыган вакытта, шулай ук экологик һәм табигатьне саклау проектларында катнашкан практик күнекмәләргә аерым игътибар бирелде.

*****



Гимназиядә 9 һәм 11 сыйныф укучылары өчен Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга педагогика институты вәкилләре белән һөнәри юнәлеш буенча очрашу узды. Чара булачак һөнәрне сайлауда өлкән сыйныф укучыларына ярдәм итүгә һәм югары белем алу мөмкинлекләре белән танышуга юнәлтелде.

*****



Махсус хәрби операциядә катнашучы сугышчыларга рәхмәт йөзеннән балалар уникаль бүләк әзерләделәр - 726 коры душ комплекты. Бу гади, ләкин файдалы душ, безнең сакчыларга сугышчан торышның катлаулы шартларында гигиенага ярдәм итәргә мөмкинлек бирәчәк. Балалар илебезне яклаучыларга хөрмәт һәм рәхмәт белдереп, һәр төргәкне җылы наз һәм кайгыртучанлык белән ясадылар. Мондый инициативалар буыннар арасындагы тирән бәйләнешне күрсәтә һәм гади булмаган ситуацияләрдә җәмгыятьнең үзара ярдәмләшүенең һәм теләктәшлегенең мөһимлеген ассызыклый. Без каһарманнарыбыз һәм аларны үз гамәлләре белән горурланабыз!

*****



Безнең гимназия бинасында Сәйяр" балалар һәм яшүсмерләр театрлары фестиваленең муниципаль этабы узды. Гимназиянең Рөстәм Муллин исемендәге балалар һәм яшүсмерләр театр кино студиясе - җиңүче!!! Әфәрин, котлыйбыз!!!!



*****

Гимназиянең 5 класс укучылары әниләр һәм педагоглар белән берлектә махсус акция оештырдылар — махсус хәрби операциядә катнашучы илебезне саклаучылар өчен файдалы үләннәр белән дәвалау чәе әзерләделәр. Туган як табигатенең яңа бүләкләрен файдаланып, мәктәп укучылары, күңелне һәм тәнне җылыта торган махсус эчемлек әзерләү өчен. Файдалы үсемлекләрне үз куллары белән җыеп киптергәннәр. Эчемлек витаминнарга һәм микроэлементларга бай, иммунитетны сакларга һәм яклаучыларыбызның кәефен күтәрергә сәләтле. Бу хезмәт-безнең заман геройларына кайгыртучанлыкны һәм игътибарны чагылдыра, Ватаныбызны яратуның ачык үрнәге булып тора. Бәләкәй чынаяк кайнар чәй йөрәк җылысын һәм тыныч киләчәккә өмет бирергә сәләтле бит. Бу инициатива кешелеклелек һәм бер-беребез турында кайгыртуның чын дәресенә әверелде, ул илебез өчен горурлык хисе һәм солдатларның батырлыгына хөрмәт уята.

*****

**"Балаларның таланты өлкәннәр ярдәм иткән җирдә ачыла!"**

Казан кооператив институтының Дардеманд исемендәге Татар мәдәнияте үзәгенең актлар залында "Туган телем"VII Халыкара укучылар конкурсында катнашкан өчен дипломнар тапшыру тантанасы булды. Быел конкурс герой - шагыйрь Муса Җәлил һәм XX гасыр башының бөек татар шагыйре, сәүдәгәр, меценат Закир Рәмиев (Дәрдеманд)

истәлегенә оештырылды. 2 класс укучысы Идрисова Раилә чакыру алды. Һәм аның сөйкемлелеге, тавышы һәм артистлыгы йолдызыбызны өченче урынга алып килде. Балалар ачышлары һәм казанышлары дөньясында юл күрсәтүче йолдызга әверелгән ата-аналарга, остазларга зур рәхмәт. Нәкъ менә сезнең иманыгыз, сабырлыгыгыз һәм кайгыртучанлыгыгыз аркасында бала аны уңыш һәм үз-үзен тормышка ашыру югарылыгына күтәрергә сәләтле канатларга ия була.



*****

Гимназиядә мәктәпкәчә һәм мәктәп коллективлары арасында инглиз телендә "English Art Festival" зона иҗат фестивале үтте. Барлык призлы урыннар да бүген бездә!!! Инглиз җыры фестивалендә: 2 класс-1 урын, 5 класс-2 урын, Гарипова Наргиза -3а һәм 6а сыйныфлары төркеме белән -3 урын. Котлыйбыз!!!






2 класс укучылары җирле водоканалга экскурсиягә бардылар. Бу - предприятие генә түгел, ә һәр кешене чиста һәм куркынычсыз су белән тәэмин итүче шәһәребезнең йөрәге. Кергәндә безне "Минзәлә районы коммуналь челтәрләре" АҖ нең ВКХ башлыгы Шәйсуваров Рәшит Михайлович каршы алды. Ул экскурсия маршруты һәм водоканал эше турында кызыклы фактлар белән таныштырды. Балаларның игътибарын төп объект-чистарту корылмалары- җәлеп итте. Монда суны чистартуның бөтен процессын күрделәр: елгадан беренчел коймадан алып безнең краннарга керә торган соңгы продуктка кадәр. Механик чистартуның ничек баруын белделәр: химик чистарту, биологик чистарту. Автоматлаштырылган су сыйфатын контрольдә тоту системалары, датчиклар һәм мониторлар – болар барысы да югары дәрәҗәдәге куркынычсызлык һәм ышанычлылык тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Бу экскурсия балаларда онытылмас тәэсир калдырды һәм эшнең никадәр мөһим, катлаулы булуын аңларга ярдәм итте.



*Рубриканы Галиева Язгөл әзерләде*